**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ**
**КАРАРЫ**

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының уналтынчы утырышы каравына кертелә торган мәсьәләләр турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы КАРАР БИРӘ:

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының уналтынчы утырышы каравына түбәндәге мәсьәләләрне кертергә:

1. Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларын сайлау турында.
2. «Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 25 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 132-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
3. «Федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бюджет кредитлары бирү турындагы килешүләргә өстәмә килешүләр раслау хакында» 131-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
4. «2021 елга, 2022 һәм 2023 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 124-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
5. «2021 елга, 2022 һәм 2023 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» 125-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
6. «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы кайбер закон актларының (закон актлары нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану хакында» 80-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (III укылыш).
7. «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 110-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (II укылыш).
8. «Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына 2020 елгы Бөтенроссия халык санын алуны әзерләү һәм үткәрү буенча Россия Федерациясе вәкаләтләрен

бирү турында» 118-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

9. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 128-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

10. «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законына һәм Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 129-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

11. «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 130-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

12. «Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 28 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 126-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

13. «Җир асты байлыклары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 119-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

14. «Авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 123-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

15. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының үз көчен югалтуын тану турында» 120-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

16. «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына һәм «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 102-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

17. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм «Тәмәкесез никотинлы продукцияне, никотин кертү электрон системаларын балигъ булмаганнарга сатуны тыю турында һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының үз көчен югалтуын тану турында» 121-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

18. «Физик культура һәм спорт турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 133-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

19. «Фән һәм фәнни эшчәнлек турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 127-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

20. Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсе эшчәнлеге турында мәгълүмат.

21. «Россия Федерациясе Торак кодексына үзгәрешләр кертү турында» 983724-7 номерлы федераль закон проекты хакында (торак милекчеләре ширкәте конференциясе институтын гамәлгә кертү өлешендә).

22. «Россия Федерациясе Торак кодексының 57 статьясына үзгәреш кертү турында» 991858-7 номерлы федераль закон проекты хакында (гражданның язма ризалыгы белән башка торак пункт чикләрендә торак урын бирү мөмкинлеген билгеләү өлешендә).

23. «Россия Федерациясе Торак кодексының 157 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 1025645-7 номерлы федераль закон проекты хакында (коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен түләүне исәпләп чыгару тәртибен бозган өчен торак йорт милекчесе алдындагы җаваплылыкны билгеләү өлешендә).

24. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 4.1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 1008818-7 номерлы федераль закон проекты турында (административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе субъекты законының тиешле статьясында (статьясы өлешендә) билгеләнгән административ штрафның минималь күләменнән кимрәк күләмдәге административ җәза билгеләү мөмкинлеге хакында).

25. «Россия Федерациясенең аерым закон актларына янгын куркынычсызлыгы өлкәсендәге эшчәнлекне камилләштерү өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 1021307-7 номерлы федераль закон проекты хакында.

26. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына ветеринария өлкәсендә җаваплылыкны көчәйтү өлешендә үзгәрешләр кертү хакында» 1021310-7 номерлы федераль закон проекты турында (ветеринария өлкәсендә кылган хокук бозулар өчен административ җаваплылыкны камилләштерү хакында).

27. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 1023005-7 номерлы федераль закон проекты турында (файдалануы чикләнгән мәгълүматны тараткан өчен административ җаваплылыкны көчәйтү хакында).

28. «Россия Федерациясе Бюджет кодексына бюджетара трансфертлар бирүне хокукый җайга салуны камилләштерү максатларында үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Мурманск өлкә Думасының закон чыгару инициативасы хакында.

29. «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнарын оештыруның һәм аларның эшчәнлегенең гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр

кертү хакында» 1027267-7 номерлы федераль закон проекты турында (тышкы дәүләт (муниципаль) финанс контроле органнары эшчәнлеген хокукый җайга салуны камилләштерү максатларында).

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2020 елның 22 октябре
№ 634-VI ДС